РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ГЛАВА САБИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

САБА МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШЛЫГЫ

ПОСТАНОВЛЕНИЕ КАРАР

06.02.2020 № 18-п

Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссиясен төзү турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Татарстан Республикасында иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү буенча эшчәнлекне оештыру турында”гы 2009 елның 29 июлендәге 631 номерлы карарын үтәү йөзеннән

КАРАР БИРӘМ:

1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссиясен төзергә.

2. Түбәндәгеләрне расларга:

– Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссиясе составы;

– Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссиясе турында Нигезләмә.

3. Әлеге карарны Интернет челтәрендә - Татарстан Республикасының Хокукый мәгълүматлар турындагы http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында бастырып чыгарырга.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Р.Н. Минниханов

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы
Башлыгының
06.02.2020
18-п номерлы карары белән
РАСЛАНГАН

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссиясе турында Нигезләмә**

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү мәсьәләләре буенча Ведомствоара комиссиясе (алга таба - Ведомствоара комиссия) Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башлыгы каршындагы даими эшләүче координация органы булып тора һәм Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, граждан җәмгыяте институтлары, массакүләм мәгълүмат чаралары һәм башка оешмалар белән иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү мәсьәләләре буенча эшчәнлеген координацияләүне һәм үзара хезмәттәшлеген оештыруны тәэмин итә.

1.2. Ведомствоара комиссия үз эшчәнлегендә федераль законнарга, Татарстан Республикасы законнарына, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының муниципаль хокукый актларына, шулай ук иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерүгә ярдәм итүне оештыру буенча ведомствоара эшче төркем турындагы Нигезләмәгә таяна.

1.3. Ведомствоара комиссия эшчәнлеге ресоциальләштерүдә ярдәм итү күздә тотыла торган затларның иреклелек һәм ихтыяр белдерү принципларына нигезләнә.

## 2. Ведомствоара комиссиянең төп бурычлары

Ведомствоара комиссиянең төп бурычлары булып түбәндәгеләр тора:

2.1. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районында иректән мәхрүм итү рәвешендә җинаять җәзасына тартылган һәм (яки) җинаять-хокукый характердагы башка чараларга дучар ителгән затларны җәмгыятькә реинтеграцияләү максатларында, социаль-икътисадый, педагогик, хокукый характердагы чаралар комплексын гамәлгә ашыру,шул исәптән:

пенитенциар озата бару;

һөнәри юнәлеш һәм хезмәт адаптациясе;

торакка кагылышлы һәм көнкүреш мәсьәләләрен җайлау,урнаштыру ;

медицина ярдәме;

психологик ярдәм;

югалган туганлык һәм башка социаль элемтәләрне торгызуда ярдәм итү;

иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциализацияләүнең башка формалары.

2.2. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы җирле үзидарә органнарының Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, граждан җәмгыяте институтлары, массакүләм мәгълүмат чаралары һәм башка оешмалар белән иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү мәсьәләләре буенча эшчәнлеген координацияләүне һәм үзара хезмәттәшлеген тәэмин итү.

2.3. Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларның республика регистрының муниципаль сегментын алып бару.

2.4. Яңадан (рецидив) җинаятьчелеккә баруны кисәтү.

2.5. Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы территориясендә иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү һәм хезмәт белән интеграцияләү буенча алып барыла торган эш турында җәмәгатьчелеккә мәгълүмат бирү.

**3. Ведомствоара комиссия вәкаләтләре**

Ведомствоара комиссия үзенә йөкләнгән бурычларны үтәү максатларында түбәндәге вәкаләтләрне гамәлгә ашыра:

3.1. Шәхси тәртиптә ресоциализацияләүдә ярдәм күрсәтүгә ризалык биргән затларның социаль хәлен карый һәм анализлый.

3.2. Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затны, законнарда каралган дәүләт һәм муниципаль ярдәм механизмнарын, башка оешмаларның һәм граждан җәмгыяте институтларының мөмкинлекләрен исәпкә алып, яңадан социальләштерүнең индивидуаль программасын эшли. Реабилитация программасында каралган чараларның һәрберсен тормышка ашыру өчен җаваплы затларны, аларны тормышка ашыру срокларын билгели.

3.3. Ресоциализация буенча үткәрелгән чараларның нәтиҗәләрен һәм файдасын анализлый.

3.4. Түбәндәге очракларда шәхси ресоциализация программасын гамәлгә ашыруны туктату турында Карар кабул итә:

тотрыклы уңай нәтиҗәләргә ирешкән очракта;

зат Саба муниципаль районыннан читкә даими яшәү урынына күчеп киткән очракта (зат Татарстан Республикасы чикләрендәге башка муниципаль районга күчеп киткән очракта, күрсәтелгән факт турында мәгълүмат, затка карата булган материаллар белән бергә, Татарстан Республикасы тиешле муниципаль районының ведомствоара комиссиясенә җибәрелә.);

ресоциализацияләүдә ярдәм итүдән баш тарту турында затның гаризасын алган очракта;

ресоциализацияләү буенча шәхси программаны алга таба гамәлгә ашыру мөмкинлеге булмаган бүтән очракларда.

3.5. Саба муниципаль районында яңадан (рецидив) җинаятьчелеккә баруны кисәтү мәсьәләләрен хокукый җайга салуны камилләштерү буенча тәкъдимнәр әзерли, аларны вәкаләтле органнарга, вәкаләтле вазыйфаи затларга җибәрә.

3.6. Ведомствоара комиссия түбәндәге хокукларга ия:

3.6.1. Үз компетенциясе кысаларында Саба муниципаль районы җирле үзидарә органнары, шулай ук дәүләт хакимияте органнары, башка оешмалар һәм гражданлык җәмгыяте институтлары тарафыннан үтәлергә тәкъдим ителгән карарлар кабул итәргә;

3.6.2. Җинаять яки административ җаваплылыкка китерә торган законны бозу билгеләре ачыкланган очракта, гаепле затларны җаваплылыкка тарту турындагы мәсьәләне хәл итү өчен хокук саклау органнарына тиешле документларны һәм материалларны җибәрергә.

3.7. Ведомствоара комиссия үз компетенциясе чикләрендә түбәндәгеләр белән хезмәттәшлек итә:

3.7.1. Иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны исәпкә алу мәсьәләләре буенча Россия Федерациясе җәзаларын үтәтү Федераль хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча Идарәсе белән;

3.7.2. Эчке эшләр органнары белән түбәндәге мәсьәләләр буенча:

- иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны исәпкә алу;
- шәхси профилактик эш үткәрү ;
- хокукый белемнәрне пропагандалауда катнашу;

3.7.3. Татарстан Республикасы Хезмәт, мәшгульлек һәм социаль яклау министрлыгы һәм аның карамагындагы учреждениеләр белән (социаль яклау бүлекләре, халыкны эш белән тәэмин итү үзәкләре, социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләре) түбәндәге мәсьәләләр буенча:

- “Дәүләт социаль ярдәме турында”гы 1999 елның 17 июлендәге 178-ФЗ номерлы Федераль законны һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының “Дәүләт социаль ярдәме турында, шул исәптән социаль контракт нигезендә, Татарстан Республикасында дәүләт социаль ярдәме күрсәтү турында”гы 2014 елның 2 сентябрендәге 635 номерлы карарын гамәлгә ашыру кысаларында, иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларга матди ярдәм күрсәтү;
- иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затлар арасыннан социаль хезмәтләр алучылар белән билгеле бер яшәү урыны булмаган затлар өчен социаль адаптация үзәкләрендә профилактик эш;
- социаль хезмәт күрсәтү учреждениеләрендә иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән балигъ булмаганнарны, шулай ук ирегеннән мәхрүм итүгә бәйле булмаган җәзаларга хөкем ителгән балигъ булмаган гражданнарны социаль адаптацияләү;
- хезмәт базары,вакансияләр турында мәгълүмат бирү юлы белән иректән мәхрүм ителү урыннарыннан азат итүгә әзерләнүче затларны ресоциализацияләүдә булышлык күрсәтү;
- эшчәнлек (һөнәр), эшкә урнашу, һөнәри белем бирү өлкәсен сайлау максатларында һөнәри юнәлеш буенча бушлай дәүләт хезмәтләре күрсәтү, билгеләнгән тәртиптә эшсез дип танылган күрсәтелгән категория затларга - эшсез гражданнарга психологик ярдәм күрсәтү, хезмәт базарында эшсез гражданнарны социаль адаптацияләү, һөнәри укыту һәм өстәмә һөнәри белем бирү буенча бушлай дәүләт хезмәтләре күрсәтү;
- иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән гражданнарга туры килә торган эш эзләүдә ярдәм итү;

– эш бирүчеләрне, иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән эшкә урнашучы затларны кызыксындыру чаралары;

3.7.4. Территориаль сәламәтлек саклау идарәсе (булганда), беренчел медик-санитар ярдәм, профилактик һәм диспансер күзәтүен оештыру мәсьәләләре буенча сәламәтлек саклау учреждениеләре белән;

3.7.5. Үз компетенциясе нигезендә дәүләт хакимиятенең башка органнары, җирле үзидарә органнары, оешмалар, граждан җәмгыяте институтлары белән хезмәттәшлек итә.

## 4. Ведомствоара комиссияне төзү тәртибе

4.1. Ведомствоара комиссия, комиссия рәисе, аның урынбасары, сәркатибе һәм комиссия әгъзалары составында төзелә.

4.1.1. Ведомствоара комиссия рәисе:

– ведомствоара комиссия эшчәнлегенә гомуми җитәкчелек итүне гамәлгә ашыра;

– хәлиткеч тавыш бирү хокукына ия булып ведомствоара комиссия утырышын алып бара;

– ведомствоара комиссиянең чираттагы утырышының көн тәртибен раслый;

– үз вәкаләтләре кысаларында ведомствоара комиссия әгъзаларына йөкләмәләр бирә;

– ведомствоара комиссия тарафыннан кабул ителгән документларга кул куя;

– ведомствоара комиссиягә йөкләнгән бурычларны үтәү өчен шәхси җаваплылык тота.

4.1.2. Ведомствоара комиссия сәркатибе:

– ведомствоара комиссия рәисе йөкләмәләрен үти;

– ведомствоара комиссия утырышының көн тәртибен формалаштыра, аның утырышына кирәкле материалларны, тиешле карарлар проектларын әзерләү эшен координацияли, комиссия утырышы беркетмәсен алып бара;

– ведомствоара комиссия әгъзаларына һәм аның утырышына чакырылган затларга ведомствоара комиссия утырышының урыны, вакыты һәм көн тәртибе турында хәбәр итә, аларны кирәкле материаллар белән тәэмин итә;

– Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының җирле үзидарә органнарына җәза үтәү системасы учреждениеләре администрацияләреннән алына торган, затны азат итү турында, аның торагы, эшкә сәләте һәм булган белгечлекләре барлыгы турында мәгълүмат җыю һәм гомумиләштерүне гамәлгә ашыра;

– иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затлардан ресоциализациягә ярдәм итү турында гаризалар кабул итүне гамәлгә ашыра;

– ресоциализация программасының һәр катнашучысына шәхси ярдәм күрсәтү картасын һәм шәхси эш рәсмиләштерә, аңа шәхси ресоциализация программасы чараларын үтәү буенча документлар һәм белешмәләр кертелә;

– ирекләреннән мәхрүм ителгән затларның Республика регистрының муниципаль сегментын алып бара;

– муниципаль берәмлекләрнең җирле үзидарә органнарыннан, дәүләт хакимияте органнарыннан, иҗтимагый һәм башка оешмалардан һәм вазыйфаи затлардан Ведомствоара комиссия эшчәнлеге өчен кирәкле документлар, материаллар һәм мәгълүмат соратып ала;

– Ведомствоара комиссия утырышлары беркетмәләрен төзи;

– утырышлар нәтиҗәләре буенча мәгълүматлар, Ведомствоара комиссиясе рәисенең йөкләмәләрен үтәүне оештыра;

– Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы халкына ведомствоара комиссия функцияләре, аның эшчәнлеге нәтиҗәләре турында мәгълүмат бирүне оештыра.

4.2. Ведомствоара комиссия составы Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башлыгының карары белән раслана.

4.3. Ведомствоара комиссия составына Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының җирле үзидарә органнары, шулай ук Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте органнары, федераль башкарма хакимият органнарының территориаль органнары, социаль яклау органнары, сәламәтлек саклау учреждениеләре, мәгариф оешмалары вәкилләре керә ала (килешү буенча).

4.4. Ведомствоара комиссия составына элегрәк иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән, ресоциализациянең уңай тәҗрибәсе булган затлар кертелергә мөмкин.

4.5. Ведомствоара комиссия утырышларында Саба районы прокуратурасы вәкиле катнаша ала.

4.6. Ведомствоара комиссия утырышына дәүләт хакимияте органнары, Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы җирле үзидарә органнары, шулай ук ведомствоара комиссия составына кермәгән башка оешмалар, граждан җәмгыяте институтлары һәм массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре чакырыла ала.

4.7. Ведомствоара комиссия эшендә катнашу иҗтимагый башлангычларда гамәлгә ашырыла.

## 5. Ведомствоара комиссия эшчәнлеген оештыру һәм аның эш тәртибе

5.1. Ведомствоара комиссия эше даими нигездә алып барыла.

5.2. Ведомствоара комиссия утырышлары, иректән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затлардан ресоциальләштерүдә ярдәм күрсәтү турында килгән гаризаларга бәйле рәвештә, әмма айга бер тапкырдан да ким булмаган күләмдә уздырыла. Кирәк булган очракта, ведомствоара комиссия рәисе, аның урынбасары, шулай ук ведомствоара комиссия әгъзасы инициативасы буенча (ведомствоара комиссия рәисе белән килештереп һәм сәркәтип тәкъдиме буенча) Ведомствоара комиссиянең чираттан тыш утырышлары үткәрелергә мөмкин.

5.3. Ведомствоара комиссия утырышларын ведомствоара комиссия рәисе, ә ул булмаганда яисә аның кушуы буенча ведомствоара комиссия рәисе урынбасары алып бара.

5.4. Ведомствоара комиссия утырышы вакыты һәм урыны турында, утырыш көненә кадәр кимендә бер тәүлек кала, ресоциальләштерүдә ярдәм күрсәтү турында

гариза кергән затларга, аларның туганнарына, утырышларда катнашулары максатчан була дип кабул ителгән башка затларга хәбәр ителә.

5.5. Ведомствоара комиссия утырышының вакыты һәм урыны турында Саба районы прокурорына хәбәр ителә.

5.6. Ведомствоара комиссия утырышы анда аның составындагы кешеләрнең яртысыннан артыгы катнашу шарты белән хокуклы була.

5.7. Ведомствоара комиссия карарлары тәкъдим итү характерына ия һәм утырышта катнашучыларның гади күпчелек тавышы белән ачык тавыш бирү юлы белән кабул ителә. Тавышлар тигез булганда утырышта рәислек итүче тавышы хәлиткеч булып тора.

5.8. Ведомствоара комиссия әгъзалары утырышларда карала торган мәсьәләләр турында фикер алышканда тигез хокукларга ия.

5.9. Ирektән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән зат теләге буенча утырыш әлеге Нигезләмәнең 4.6 пунктында күрсәтелгән затларны чакырмыйча гына уздырыла.

5.10. Ведомствоара комиссия әгъзалары, комиссия утырышында каралган мәсьәләләр турында белешмәләрне, әлеге мәсьәләләргә кагылышлы затларның ризалыгыннан башка игълан итәргә хокуклы түгел.

Гражданнарның шәхси тормышы турында мәгълүматлар тараткан өчен ведомствоара комиссия әгъзалары законнар нигезендә җаваплы.

5.11. Ведомствоара комиссия эшен массакүләм мәгълүмат чараларында яктырту максатларында, ведомствоара комиссия рәисе рөхсәте белән, шәхси мәгълүматларны күрсәтмичә, тиешле мәгълүматны массакүләм мәгълүмат чараларына бирү рөхсәт ителә.

Татарстан Республикасы
Саба муниципаль районы
Башлыгының
06.02.2020
18п номерлы карары белән
РАСЛАНГАН

**Татарстан Республикасы Саба муниципаль районының irектән мәхрүм итү урыннарыннан азат ителгән затларны ресоциальләштерү мәсьәләләре буенча ведомствоара комиссиясе составы**

| | |
|---|---|
| Минниханов Р.Н. | Татарстан Республикасы Саба муниципаль районы Башлыгы, комиссия рәисе; |
| Ишниязов М.Р. | Саба муниципаль районы Башкарма комитеты Җитәкчесе, комиссия рәисе урынбасары; |
| Шайдуллин Л.И. | Саба муниципаль районы Башлыгының коррупциягә каршы тору мәсьәләләре буенча ярдәмчесе, комиссия секретаре; |
| Эшче төркем әгъзалары: | |
| Әхмәтов А.Г. | Саба районы мөхтәсибе (килешү буенча); |
| Габтерахманов Д. Р. | “Саба районы халкын эш белән тәэмин итү үзәге” ДКУ директоры (килешү буенча); |
| Гарипов И. Р. | Саба муниципаль районы Башкарма комитетының яшьләр эшләре һәм спорт бүлеге начальнигы; |
| Гафиятуллин А. Т. | Россия Эчке эшләр министрлыгының Саба районы буенча бүлегенең миграция мәсьәләләре бүлеге начальнигы, полиция майоры (килешү буенча); |
| Заһидуллин Р. Ф. | Саба муниципаль районы Башкарма комитетының мәдәният бүлеге начальнигы; |
| Латыйпов С. З. | Саба районы буенча Эчке эшләр бүлегенең җәмәгать тәртибен саклау буенча полиция начальнигы урынбасары, полиция майоры (килешү буенча); |
| Петров А. А. (батюшка Артемий) | Мәскәү дини оешмасы Патриархатының мәхәллә советы һәм Казан Изге Ана Иконасы Мәхәлләсе башлыгы (килешү буенча); |
| Сабиров Р. Х. | Саба муниципаль районы Ветераннар (пенсионерлар) советының Иҗтимагый оешмасы рәисе; |
| Сәлимов И. Р. | Россия ҖҮФХИнең ТР буенча идарәсенең Арча муниципальара филиалы өлкән инспекторы, эчке хезмәт капитаны (килешү буенча); |
| Шакиров И. Ф. | “Саба муниципаль районы Башкарма комитетының Мәгариф идарәсе” МКУ начальнигы; |
| Йосыпов М. Р. | “Саба РҮХ” ДАССОның баш табибы (килешү буенча). |